ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

“Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында” 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 3, № 9; 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның беренче өлешендәге өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өчен кирәкле көчләрне һәм чараларны әзерләү һәм аларны әзер килеш тоту, шулай ук гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә халыкны әзерләү;”;

2) 10 статьяда:

а) икенче абзацта “яклауны тәэмин итү” сүзләрен “яклау” сүзенә алмаштырырга;

б) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә халыкны әзерләү;”;

3) 16 статьяда:

а) икенче өлештә “мәгариф оешмаларында” сүзләрен “белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда” сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар җитәкчеләре һәм аларның башка хезмәткәрләре гадәттән тыш хәлләрдәге гамәлләргә әзерлекне мәгариф оешмаларында төп һөнәри белем бирү программалары буенча узалар.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 07 мае
№ 28-ТРЗ